РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЗАКЛАР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422722, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Казаклар авылы, Совет ур., 5

СОВЕТ КАЗАКЛАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422722, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Казаклар, ул.Советская, 5

Тел./факс: +7(84365) 63-4-30, e-mail:Kazak.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 август 2020 г.** **№ 153**

**Казаклар авыл җирлегенең Биектау муниципаль районы Советына тапшырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү Вәкаләтләре исемлегенә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында», 2019 елның 25 декабрендәге 110-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Казаклар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Казаклар авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 мартындагы 106 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Казаклар авыл җирлеге Советыннан Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» карары белән расланган Казаклар авыл җирлегенең Биектау муниципаль районы Советына тапшырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү Вәкаләтләре исемлегенең 1 нче кушымтасының 2.18 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«2.18. килеп туган гадәттән тыш хәлләрне муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләргә кертү, гадәттән тыш хәлләрдә эвакуация чаралары уздыру һәм аларны үткәрүне оештыру турында карарлар кабул итү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Идрисов